**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

29 октябрь 2025ел | № 396

**Әтнә районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 06.08.2021 ел, № 258 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 31.07.2025 елның 353-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Әтнә район башкарма комитетының «Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 06.08.2021 ел, № 258 карарына (Әтнә район башкарма комитетының 17.09.2024 ел, №415, 15.08.2025 ел, №300 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар преамбуласында «02.11.2010 ел, № 880 «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» сүзләрен «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 28.02.2022 ел, № 175» сүзләренә алмаштырырга»;

1.2. Административ регламентның 2.3.4. нче пунктның беренче абзацын түбәндәге эчтәлектә яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.3.4. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турындагы карар җир кишәрлеге турында белешмәләрне БДКМРГА кертү өчен нигез булып тора һәм басылып чыккан көннән алып бер ел дәвамында гамәлдә була. Россия Федерациясе Җир кодексы 39.15 статьясының 10 пунктында каралган очракта, мондый карарның гамәлдә булу срогы ике ел тәшкил итә.»;

1.3. Административ регламентның 2.5.2. нче пунктның 5 нче подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон

актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән бакчачылык яисә коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәте әгъзалары Реестры, әгәр җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында яисә җир кишәрлеген мондый ширкәткә түләүсез файдалану.»;

1.4. Административ регламентның 2.7.3. пунктында «7 эш көне» сүзләрен «10 көн» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. Административ регламентның 2.8.3.2. пунктының 3 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килде, әлеге ширкәт әгъзасының мондый гариза белән мөрәҗәгать итү очракларыннан тыш (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык яисә яшелчә бакчасы булса) йә бакчачылык яисә коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтендә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган, федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир кишәрлеген беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алуга йә Җир кодексының 39_18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга хокуклы граждан (әгәр мондый җир кишәрлеге бакча кишәрлеге булса), шулай ук гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып барган территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса);»;

1.6. Административ регламентның 2.8.3.2. пунктының 13 нче подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Җир кодексының 39_18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә индивидуаль торак төзелеше, торак пунктлар чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәрнамә урнаштырылган;»;

1.7. Административ регламентның 2.8.3.2. пунктының 16 пунктчасында «иң чик» сүзен төшереп калдырырга;

1.8. Административ регламентның 4 һәм 5 бүлекләрен үз көчләрен югалткан дип танырга.

Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге хокукый нормациянең рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов